КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 28 февраль г.Казань № 119

Хезмәт базарында таләп ителә торган һөнәрләр, белгечлекләр исемлеге нигезендә инвалидларның һөнәри укуын, өстәмә һөнәри белем алуын оештыру тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Хезмәт базарында таләп ителә торган һөнәрләр, белгечлекләр исемлеге нигезендә инвалидларның һөнәри укуын, өстәмә һөнәри белем алуын оештыру тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы<br>Премьер-министры<br>вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2025 ел, 28 февраль, 119 нчы
карары белән расланды

Хезмәт базарында таләп ителә торган һөнәрләр, белгечлекләр исемлеге нигезендә инвалидларның һөнәри укуын, өстәмә һөнәри белем алуын оештыру тәртибе

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы, «Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру турында» 2006 елның 19 июнендәге 39-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $2^1$ статьясындагы 3 өлеше, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Инвалидларга дәүләт ярдәме чараларын күрсәткәндә махсус чараларны гамәлгә ашыру буенча методик тәкъдимнамәләрне раслау турында» 2024 елның 12 ноябрендәге 614 номерлы боерыгы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан расланган хезмәт базарында таләп ителә торган һөнәрләр, белгечлекләр исемлеге (алга таба – Һөнәрләр исемлеге) нигезендә инвалидларның һөнәри укуын, өстәмә һөнәри белем алуын (алга таба – укыту) оештыру тәртибен билгели.

2. Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган инвалидларны (алга таба – нвалидлар) Һөнәрләр исемлеге нигезендә укытуны оештыру «Татарстан Республикасының Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесе (алга таба – Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3. Инвалидларны укытуның төп максаты – аларның мәшгульлеген тәэмин итү өчен белемнәр, компетенцияләр һәм күнекмәләр алу яисә булганнарын арттыру, хезмәт базарында аларның конкуренциягә сәләтен арттыру, икътисадый бәйсезлекне тормышка ашыру һәм җәмгыятькә интеграцияләү.

4. Һөнәрләр исемлеге нигезендә инвалидларны укытуны оештыру Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан раслана торган эшсез гражданнарны һөнәри укытуны, аларга өстәмә һөнәри белем бирүне (башка җирлектә укытуны кертеп) оештыру буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеге стандартына һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан эшсез гражданнарның һәм башка категорияләрдәге гражданнарның һөнәри укуын, өстәмә һөнәри белем алуын оештыру турындагы нигезләмәне раслау турында» 2024 елның 14 сентябрендәге 1263 номерлы карары белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте органнары тарафыннан эшсез гражданнарның һәм башка категорияләрдәге гражданнарның һөнәри укуын, өстәмә һөнәри белем алуын оештыру турындагы нигезләмәгә таянып гамәлгә ашырыла.

5. Һөнәрләр исемлеге буенча инвалидларны укытуны оештыру Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан раслана торган гражданнарның һөнәри юнәлешен оештыру буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру стандартында каралган тәртиптә һөнәри эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәри белем алу, өстәмә һөнәри белем алу максатларында, һөнәри эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнашу, һөнәри уку, өстәмә һөнәри белем алу максатларында гражданнарның һөнәри юнәлеш алуын оештыру буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру эшчәнлеге стандартында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла торган һөнәри юнәлеш бирү нәтиҗәләре (аларда инвалидның һөнәри укуы, өстәмә һөнәри белем алуы максатка ярашлы булу турында мәгълүмат һәм инвалидка тәкъдим ителә торган мәгариф программалары исемлеге бирелә);

Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан «Работа в России» халыкны эш белән тәэмин итү һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә бердәм цифрлы платформасын (алга таба – бердәм цифрлы платформа) кулланып, ведомствоара электрон хезмәттәшлек тәртибендә «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан соратыла торган гражданның инвалидлыгы турында белешмәләр (инвалидны реабилитацияләү яки абилитацияләү буенча индивидуаль программадан өземтә).

6. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге укуда булган инвалидка карата, бердәм цифрлы платформаны кулланып, ведомствоара электрон хезмәттәшлек тәртибендә ведомствоара рәсми сорауларны түбәндәгеләргә җибәрү юлы белән, инвалид укып бетергәннән соң бер ай узгач, ай саен өч ел дәвамында мондый инвалидның эш белән тәэмин ителеше турында белешмә булдыра:

Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондына хезмәт эшчәнлеге турында, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны турында белешмәләр хакында;

Федераль салым хезмәтенә Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр хакында, юридик затларның гамәлгә куючылары (аларда катнашучылар) булган гражданнар турында, һөнәри керемгә салым түләүченең (үзмәшгульнең) статусы турында белешмәләр хакында.

______________________